**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6801**
**15.10.2021**

Башкарма комитетның «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5732 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 23 апрелендәге 2862 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 17727,48 мең сум: 2021 ел – 5909,16 мең сум, 2022 ел - 5909,16 мең сум, 2023 ел - 5909,16 мең сум күләмендә» сүзләрен «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 17027,48 мең сум: 2021 ел – 5209,16 мең сум, 2022 ел - 5909,16 мең сум, 2023 ел - 5909,16 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары (мең сум) | | | барлыгы (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | |
| | муниципаль бюджет | 5209,16 | 5909,16 | 5909,16 | 17027,48 |
| | республика бюджеты | - | - | - | - |
| | федераль бюджет | - | - | - | - |
| | башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | барлыгы | 5209,16 | 5909,16 | 5909,16 | 17027,48 |

- 5 бүлекнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ үсеше, шул исәптән өстәмә профессиональ белем бирү (квалификация күтәрү, яңадан профессиональ әзерлек) буенча чаралар оештыру | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2021-2023 еллар | Тиешле елда квалификация күтәрү, яңадан профессиональ әзерлек үткән муниципаль хезмәткәрләрнең өлеше, штат саны % | 33 % | 33 % | 33 % | 33 % | 1203,65 (муниципаль бюджет) | 1903,65 (муниципаль бюджет) | 1903,65 (муниципаль бюджет) |

- 6 пунктта «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 17727,48 мең сум: 2021 ел – 5909,16 мең сум, 2022 ел – 5909,16 мең сум, 2023 ел – 5909,16 мең сум күләмендә» сүзләрен «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 17027,48 мең сум: 2021 ел – 5209,16 мең сум, 2022 ел – 5909,16 мең сум, 2023 ел – 5909,16 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов